**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

_______438-п____ _16.06.2014________

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында гомумтаралган файдалы казылма запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләренең геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматларына дәүләт экспертизасы үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2013 елның 18 ноябрендәге 665-п номерлы боерыгы белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының норматив-хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында **б о е р ы к б и р ә м**:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында гомумтаралган файдалы казылма запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләренең геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматларына дәүләт экспертизасы үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2013 елның 18 ноябрендәге 665-п номерлы боерыгы белән расланган административ регламентына (алга таба - Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Регламентның 1 бүлегендә:

1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектлары, шул исәптән гадәти ширкәттә катнашучылар, чит ил гражданнары, юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).»;

1.4 пунктында:

алтынчы абзацны алып ташларга;

аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, яңа абзац белән тулыландырырга:

“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын төзү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 880 номерлы карары белән;

1.5 пунктында:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Гомумтаралган файдалы казылмалар – пространстволы һәм генетик рәвештә явым-төшем, магматик яки метаморфоген токымнар белән бәйле, конкрет төбәк шартларында еш очрашучанлыгы, сизелерлек таралу мәйданнары белән сыйфатланучы яки руда, металл булмаган, янучан файдалы казылма ятмаларының табыла торган һәм сыйдырышлы токымнарында тупланучы, сыйфаты һәм радиация куркынычсызлыгы буенча гамәлдәге ГОСТлар, ОСТлар, ТУ, СНиПларның таләпләренә җавап бирүче, әзер продукцияне алу өчен чимал чыганагы булган һәм җирле җитештерү ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен хезмәт итүче металл булмаган һәм янучан файдалы казылмалар. Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Табигый ресурслары министрлыгының 2006 елның 18 маендагы 27-р номерлы һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 2006 елның 18 маендагы 623-р номерлы әмернамәсе белән расланган  Татарстан Республикасы буенча гомумтаралган файдалы казылмалар исемлеге гамәлдә.”;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Җир асты биләмәсеннән файдаланучы – эшмәкәрлек эшчәнлеге субъекты, шул исәптән гади ширкәт катнашучысы, чит ил гражданы, юридик зат.”;

түбәндәге редакциядә бәян итеп, яңа абзац белән тулыландырырга:

“Әлеге регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) дигәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гарызнамә аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 пункты). Гариза стандарт бланкта тутырыла;”

Регламентның 2 бүлегендә:

2.3, 2.9 һәм 2.10 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.3 Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсен тасвирлау | Дәүләт экспертизасы бәяләмәсе. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат. | 11.11.05, № 69 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Гомумтаралган файдалы казылма запасларына, файдалануга тапшырыла торган җир асты биләмәләре турында геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматларына дәүләт экспертизасы үткәрү турында нигезләмә, 24 пункт; 11.12.06 № 278 Россия ТРМ Боерыгы белән расланган  каты |

| | | |
|---|---|---|
| | | файдалы казылма чыганаклары запаслары һәм фараздагы ресурслар классификациясе |
| 2.9 Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктату яки аны күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктату өчен нигезләр Россия Федерациясе законнарында каралмаган.<br>Законнарда каралган документларның берсен тапшырмау дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора. | 11.11.05, № 69 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Гомумтаралган файдалы казылма запасларына, файдалануга тапшырыла торган җир асты биләмәләре турында геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматларына дәүләт экспертизасы үткәрү турында нигезләмә, 10 пункт; |
| 2.10 Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алуның тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт экспертизасы үткәрүгә түләү җир асты биләмәсеннән файдаланучылар тарафыннан материаллар тапшырганчы хәл ителә һәм гомумтаралган файдалы казылма чыганакларыннан торучы, файдалы казылма чыгаруга бәйле булмаган, җир асты корылмаларын төзү һәм алардан файдалану өчен кулланыла торган җир асты биләмәләре, җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләре, шулай ук җирле әһәмияттәге биләмәләр ягыннан әлеге экспертизаны үткәргән өчен Татарстан Республикасы кеременә кабул ителә. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен түләү күләме Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 11.02.05 № 69 Карары белән билгеләнгән (27 пункт һәм 1 һәм 2 кушымталар). | 11.11.05, № 69 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Гомумтаралган файдалы казылма запасларына, файдалануга тапшырыла торган җир асты биләмәләре турында геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматларына дәүләт экспертизасы үткәрү турында нигезләмә, 10, 27 пункт, 1 һәм 2 кушымталар; |

“Стандарт таләбе эчтәлеге” графасында:

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, яңа абзац белән тулыландырырга:

“дәүләт экспертизасы өчен түләүне раслаучы документлар”;

2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, яңа абзац белән тулыландырырга:

“Дәүләт хезмәтен күрсәтү күпфункцияле үзәкләр аша башкарылмый.”;

2.16 пунктындагы икенче абзацны алып ташларга;

“Дәүләт хезмәтен күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт” графасында:

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “11.11.05, № 69 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Гомумтаралган файдалы казылма запасларына, файдалануга тапшырыла торган җир асты биләмәләре турында геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматларына дәүләт экспертизасы үткәрү турында нигезләмә, 10 пункт.”

Регламентның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ СОСТАВЫ, АЛАРНЫ ҮТӘҮНЕҢ ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ СРОКЛАРЫ, АЛАРНЫ ҮТӘҮНЕҢ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ ЭЛЕКТРОН ФОРМАДА ҮТӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ, ҺӘМ ШУЛАЙ УК АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ КҮПФУНКЦИЯЛЕ ҮЗӘКЛӘРДӘ ҮТӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

3.1 Дәүләт хезмәтен күрсәткәндәге гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау.

3.1.1 Җирле әһәмияттәге гомумтаралган файдалы казылма запасларына, файдалануга тапшырыла торган җир асты биләмәләре турында геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматларга дәүләт экспертизасы үткәрү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

1) гариза бирүчене консультацияләү;

2) гаризаны һәм файдалы казылма запасларына дәүләт экспертизасын үткәрү турындагы материалларны кабул итү һәм теркәү;

3) файдалы казылма запасларына, файдалануга тапшырыла торган җир асты биләмәләре кишәрлекләре турында геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы бәяләмәсен раслау беркетмә белән формалаштырыла һәм министр урынбасары тарафыннан имзалана;

4) гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен юллау.

3.1.2 Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема №1 кушымтада күрсәтелгән.

3.2 Җир асты биләмәләреннән файдаланучылар Министрлыкка Татарстан Республикасы экология һәм табигый ресурслар министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары) исеменә Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан билгеләнелә торган таләпләр нигезендә әзерләнгән гомумтаралган файдалы казылма запаслары исәпләмәсе материаллары, файдалануга тапшырылган җир асты биләмәләре турында геологик, икътисади

һәм экологик мәгълүматлар һәм минераль чималга эксплуатацион кондицияләр нигезләве белән, экспертиза үткәрүгә кәгазьдә 4 нөсхәдә һәм электрон рәвештә 1 нөсхәдә заявка җибәрә. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гарызнамә бирү мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү ягыннан ярдәм итүне таләп итми.

3.2 пункты белән билгеләнүче процедура заявканы теркәгәннән соң 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: экспертизаны үткәрүгә гаризаны теркәү.

3.3 Гариза Министрлык канцеляриясендә теркәлә һәм министр урынбасарына җибәрелә. Гариза һәм файдалануга тапшырылган җир асты биләмәләренең гомумтаралган файдалы казылма запаслары исәпләмәсе, геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматлар һәм минераль чималга эксплуатацион кондицияләр нигезләве материаллары министр урынбасары тарафыннан карап тикшерелә һәм, тулылыгын, дәүләт экспертизасы үткәрү мөмкинлеген билгеләү өчен Бүлеккә җибәрелә.

3.3 пункты белән билгеләнүче процедура гаризаны теркәгәннән соң 2 эш көне дәвамында теркәлә.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаны Бүлеккә карап тикшерүгә юллау.

3.4 Бүлекнең әйдәп баручы белгече тапшырылган документларга анализ ясый, аларның тулылыгын билгели һәм бүлек башлыгына гомумтаралган файдалы казылма запасларына, файдалануга тапшырылган җир асты биләмәләре турында геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматларга һәм минераль чималның әлеге төренә эксплуатацион кондицияләр нигезләвенә дәүләт экспертизасы үткәрү мөмкинлеге турында җиткерә.

3.4. пункты белән билгеләнүче процедура 1 эш көне эчендә хәл ителә.

Процедураның нәтиҗәсе: файдалануга тапшырылган җир асты биләмәләренең гомумтаралган файдалы казылма запасларына геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматларына һәм минераль чималның әлеге төренә эксплуатацион кондицияләр нигезләвенә дәүләт экспертизасы үткәрү мөмкинлеген билгеләү.

3.5 Бүлек башлыгы материалларны карап тикшерә, министр урынбасарына материалларның тулылыгы һәм дәүләт экспертизасы үткәрү мөмкинлеге турында җиткерә һәм, гомумтаралган файдалы казылма чыганакларыннан торган җир асты биләмәләре, җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләре, шулай ук файдалы казылма чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм алардан файдалану максатында файдаланыла торган җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләре ягыннан дәүләт экспертизасы үткәрү өчен, материалларны Министр тарафыннан вәкаләт бирелгән эксперт комиссиясенә (алга таба – эксперт комиссиясе) җибәрә.

3.5 пункты белән билгеләнүче процедура 1 эш көне дәвамында хәл ителә.

Процедураның нәтиҗәсе: файдалануга тапшырылган җир асты биләмәләренең гомумтаралган файдалы казылма запасларына, геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматларына һәм минераль чималның билгеле бер төренә эксплуатацион кондицияләр нигезләвенә дәүләт экспертизасы үткәрү

мөмкинлеген билгеләү. Материалларны эксперт комиссиясенә җибәрү яки мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару.

3.6 Эксперт комиссиясе тарафыннан гомумтаралган файдалы казылма запасларына, файдалануга тапшырылган җир асты биләмәләре кишәрлекләре турындагы геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматларга һәм эксплуатацион кондицияләр нигезләвенә экспертиза үткәрү.

3.6 пункты белән билгеләнүче процедура Министрлыктан материалларны алганнан соң 10 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гомумтаралган файдалы казылма запаслары исәпләмәсе, файдалануга тапшырылган җир асты биләмәләре кишәрлекләре турында геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматларга һәм эксплуатацион кондицияләр нигезләве материалларына эксперт бәяләмәсе.

3.7 Гомумтаралган файдалы казылма чыганакларыннан торган җир асты биләмәләре ягыннан, җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләре, шулай ук файдалы казылма чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм алардан файдалану максатлары өчен кулланыла торган җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләре ягыннан дәүләт экспертизасы нәтиҗәләре дәүләт экспертизасы бәяләмәсендә бәян ителә, бәяләмәгә эксперт комиссиясе әгъзалары имза сала һәм бәяләмә Министрлыкка җибәрелә.

3.7 пункты белән билгеләнүче процедура Министрлыкка эксперт бәяләмәсен тапшырган көннән 3 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасы бәяләмәсе.

3.8 Тапшырылган дәүләт экспертизасы бәяләмәсе министр урынбасары тарафыннан раслана. Файдалы казылма запасларының, файдалануга тапшырылган җир асты биләмәләре турында геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматларның расланган дәүләт экспертизасы бәяләмәсе беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм министр урынбасары тарафыннан имзалана. Файдалы казылма запасларының, файдалануга тапшырыла торган җир асты биләмәләре турында геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматлар бәяләмәсе Министрлыкның файдалануга тапшырыла торган җир асты биләмәләре турында геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматлар бәяләмәсен раслау хакындагы беркетмәсенең аерылгысыз өлеше булып тора.

Гомумтаралган файдалы казылма чыганакларыннан торган җир асты биләмәләре, җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләре, шулай ук файдалы казылма чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм алардан файдалану максатлары өчен кулланыла торган җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләре ягыннан файдалы казылма запаслары, файдалануга тапшырылган җир асты биләмәләре турында геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматлар бәяләмәсен раслау турында беркетмә Министрлык тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә.

3.8 пункты белән билгеләнүче процедура дәүләт экспертизасы бәяләмәсен раслаган көннән 3 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: беркетмә белән расланган дәүләт экспертизасы бәяләмәсен гариза тапшыручыга бирү.

3.9 Дәүләт хезмәтен күрсәтү күпфункцияле үзәкләр аша һәм электрон рәвештә башкарылмый.”.

Административ регламентка 1 номерлы кушымтада гомумтаралган файдалы казылма запасларына, файдалануга тапшырыла торган җир биләмәләре кишәрлекләре турында геологик, икътисади һәм экологик мәгълүматларга дәүләт экспертизасын үткәрү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең блок-схемасында "электрон почта яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы аша документларны тапшыру очрагында алынган документларны кәгазьдә бастырып чыгара” сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (В.А. Тронин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен юлларга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Т.М. Акчуринга йөкләргә.

Министр А.Г. Сидоров

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ:

Министр урынбасары
Т.М. Акчурин ______________________________ «_____»___________________2014 ел.

Минераль-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгы
И.С. Фәттахов______________________________ «______» ___________________2014ел.

Хокукый тәэминат бүлеге башлыгы
В.А. Тронин ______________________________ «______» ___________________2014ел.

Каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгы
С.Г. Кулешов ______________________________ «______» ___________________2014ел.